**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ**
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 344-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 345-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
4. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 350-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 349-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.
7. «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

8. Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салуны камилләштерү зарурлыгы турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

9. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетының 2019 елның сентябреннән 2022 елның ноябренә кадәрге эш чорына хисабы.

11. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе мәгълүматы.

12. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1196104-7 номерлы федераль закон проекты турында.

13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 197803-8 номерлы федераль закон проекты турында (авыр үтелә торган җирлек, су, тау объектлары, спелеологик һәм башка объектлар буенча уза торган, тормыш өчен аеруча куркыныч тудыруга, туристларның (экскурсантларның) сәламәтлегенә һәм аларның мөлкәтенә зыян салуга бәйле булган хәрәкәт итү маршрутлары буенча мәгълүмат бирү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

14. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законның 126 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 212656-8 номерлы федераль закон проекты турында (бурычлының чираттан тыш каплана торган чыгымнары өлешендә).

15. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы кысаларында чараларны гамәлгә ашыру турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 11 ноябре
№ 1676-VI ДС